## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Тарлау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«15» ноябрь 2023 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, «2024 елда Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Тарлау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, I һәм II төркем инвалидлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәт итәргә чакырылган гражданнардан тыш, 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Тарлау авылындагы Гафиятуллин урамын асфальтлау соравы буенча 2023 елның 15 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 58 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 31 кеше, бу 53,4% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 31 катнашучысы тавыш бирә; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирә.

Язылганнардан чыгып, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Тарлау торак пунктында гражданнар җыены узган һәм аның нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. «2024 елда Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Тарлау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, I һәм II төркем инвалидлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәт итәргә чакырылган гражданнардан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Тарлау авылындагы Гафиятуллин урамын асфальтлау” - соравын кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Димтамак авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмати стендларда игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә веб - адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Димтамак авыл җирлеге башлыгы Җ.Ә.Хөснетдинов